КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 13 апрель г.Казань № 279

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарын тормышка ашыру буенча чаралар хакында» үзгәрешләр кертү хакында 2020 ел, 31 нче март, 240 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау максатларында кертелгән тыюлар һәм чикләүләр гамәлдә булган чорда хәрәкәт итүгә махсус рөхсәтнамәләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарын тормышка ашыру буенча чаралар хакында» үзгәрешләр кертү хакында 2020 ел, 31 нче март, 240 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 06 апрель, 260 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау максатларында кертелгән тыюлар һәм чикләүләр гамәлдә булган чорда хәрәкәт итүгә махсус рөхсәтнамәләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Махсуслаштырылган сервиста теркәлү шулай ук шәхси кабинет аша да гамәлгә ашырылырга мөмкин, аңа керү «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация https://covid19.tatarstan.ru сайтында бирелә (алга таба – шәхси кабинет).»;

4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"СМС-хәбәрләр аша махсуслаштырылган сервиста теркәлгән гражданнарга күрсәтелгән код шәхси кабинетка керү мөмкинлеге бирә.»;

5 пунктта:

беренче абзацка "МАКСАТ» сүзеннән соң «яисә соратып алуны шәхси кабинет аша җибәрә» сүзләрен өстәргә;

1 пунктка "/хәрби комиссариат» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

10) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенә (КФҮ)/ Россия Федерациясе Пенсия фондының (РПФ) Татарстан Республикасы буенча идарәләренә һәм клиентлар хезмәтләренә бару.

Әлеге пунктның 10 пунктчасында күрсәтелгән очракны сайлау бары тик шәхси кабинет аша гына гамәлгә ашырылырга мөмкин.»;

түбәндәге эчтәлекле 9 һәм 10 пунктлар өстәргә:

«9. «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы, 2019 яки 2020 елларда һөнәри керемгә салымны кимендә бер тапкыр түләгән гражданнар (алга таба – үзмәшгуль гражданнар) үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру максатларында чыгып йөрергә рөхсәт алырга хокуклы.

Махсусуслаштырылган сервиста теркәлгән үзмәшгуль гражданнар рөхсәт алу өчен шәхси кабинетта тиешле юлларны тутыралар.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән шартларга туры килүләре раслаганнан соң, мондый үзмәшгуль гражданнарга түбәндәге очракларның берсен сайлап алу юлы белән хәрәкәт итүнең өстәмә максатлары ачык була:

1) йомышчылар китерү;

2) җитештерү бинасына бару;

3) материаллар /чимал сатып алу;

4) җиңел таксида йөртүче буларак хезмәт күрсәтү.

10. Махсуслаштырылган сервис эшчәнлеген Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы тәэмин итә.».

2. Бу карар басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин